■ Хәзрәт вәгазе

# ТУТЫРЫРГА КИРӘК БУЛГАН ӨЧ БУШЛЫК

**Исламда тәрбиянең максаты - саф йөрәкле, Раббысын таныган, камил кешеләр җитештерүдер.**



Мөхәммәт ГАЛЛЯМОВ,
"Ихлас" мәчете имам-хатыйбы

**Газиз мөэминнәр!**

**Раббыбыз Аллаһ шулай боерды:**

وَلَا تَلْبِسُوا الْحَقَّ بِالْبَاطِلِ وَتَكْتُمُوا الْحَقَّ وَأَنْتُمْ تَعْلَمُونَ

**"Хак сүзне нәҗес-ялганга алмашмагыз. Белгән көенчә, дөреслекне яшермәгез".**

Тәрбия һәм укытудан максат, тик коры белем бирү генә түгелдер. Әгәр тәкъвәле булмыйчада гыйлеменең бер шәрәфе булса, Иблис яратылганнарның иң шәрәфлесе булыр иде.

Һәр бала дөньяга килә икән өч буш нәрсә белән берлектә килер.

Болар:

1 - Башы буштыр.

2 - Карыны (ашказаны) буштыр.

3 - Күңеле (рухы) буштыр.

Сез ошбу өч бушлыкны Аллаһ вә Рәсүленең теләгән үлчәмнәренә күрә тутырсагыз, ул бала яхшы бәндә булыр, шәхесият казаныр, Исламның адәме булыр. Карынын тутырмасагыз урлашырга тотыныр, башкаларның малына ябышыр, җәмгыяттә хозурсызлык барлыкка килер. Карынын хәрам нәрсәләр белән тутырсагыз ул заманда мәкерле һәм астыртын булыр. Хакны, хокукны танымас, яратканына юнәлмәс, гыйбәдәтләрдән ләззәт тоймас, әрсезлеккә, хыянәткә, начарлыкка, зәлемгә тартылыр һәм залимнәргә иярүчән булыр. Башын Хак белемнәре белән тутырмасагыз - җаһил, күңелен Хакка гыйшык белән тутырмасагыз мәрхәмәтсез булыр.

Болай Хактан, хакыйкаттән, диннән, иманнан һәм мөкаддәсияттән ерак булганнар, нәтиҗәдә әүлия түгел, фетнәчегә әврелер.

Пәйгамбәребез (С.Г.В.) шулай боерды:

يَكُونُ فِى آخِرِ الزَّمَانِ عُبَّادٌ جُهَّادٌ وَ قُرَّاءٌ فُسَّاقٌ

***"Ахры заманда (кыяматкә якын заманнарда) җаһил әдибләр, гөнаһлы гыйлем сәхибләре булачактыр".***

Бу хәдис шәриф: кыяматнең кубарылуына сәбәп тәшкил иткән нәрсәләрдән ике данәсенә ишарәт итә:

Билгесез һәм җаһилчә гыйбадәт иткәннәрнең булуы, гыйбадәт иткәннәрнең гыйлемгә тиешле әһәмият бирмәүләре, белем ияләренең дә гыйлемләре белән гамәл итмичә, гөнаһларга уралуы, тискәре булуларыдыр.

Шулай булгач гыйбадәтләрне белеп һәм сөеп башкару, гыйлемгә һәм галимгә тиешле игътибар бирү, гыйлем ияләренең дә гыйлемләре белән гамәл итүләре кирәктер. Белгәнегезчә мәгънәсе, асылы анлашылмыйча башкарылган гыйбадәтләр даимилеген һәм дәвамлеген саклый алмас. Гамәлсез гыйлем - җимешсез агач һәм чәчәксез бакча кебектер. Начарлык һәм гөнаһ бик ямьсез нәрсәләр. Боларны бер галимнең эшләве исә тагыда нык тупаслыктыр. Чөнки кешеләр галимнәрдән үрнәк алар.

Мөхтәрәм кардәшләрем! Рәсүл Әкрәм Әфәндебез шулай боерды:

**"Истикамәттә - тугыры юнәлештә булыгыз, истикамәт сәхибе булыгыз. Истикамәт тән булган савабның тәрләрен санап бетерә алмассыз".**

Истикамәт: саф бер иман белән Пәйгамбәребезнең китергән нигъмәтләренә әчең һәм тышың белән оюдыр.

Истикамәт: Хакка ою, Хак янәшәсендә булу, Хакны тоту, Хакның әһле хәленә килүдер.

Истикамәтле булу: Исламга таянып яшәү, Ислам даирәсендә йөрү, башка юлларга борылмау, борылдырмау, гыйбадәтләргә тиешле игътибар итү, Исламның гыйззәт, намус һәм шәүкәтен саклау димәктер.

Газиз кардәшләрем! Димәк ошбу истикамәтне тугырылыкны куәтләндерү өчен, иң башта әйткәнебезчә баланың буш булган өч урынын яхшы нәрсәләр белән тутырырга тиешлебез.

Чөнки Әфәндебез (С.Г.В.) шулай боерды:

**"Колның йөрәге истикамәттә булмыйча, иманы истикамәттә булмас. Сөйләмендә истикамәт булмаса, йөрәге истикамәттә булмас".**

Дин Исламның тәэсир һәм файдасы булуының шартлары шулар: Мөкаддәс Ислам динен яхшы белү, шөбһәләнмичә инану һәм сөю белән яшәүдер.

Нәфесләребезгә, нәселләребезгә һәм рухи кыйммәтләребезгә сәхиб булуыбыз зарурдыр.

Чөнки әхирәттә безне коткарачак бер әсәр яки нәтиҗәләр булмаган тәкъдирдә дөньядалыкта калдырган әсәрләрнең кыйммәте булмаячак. Безне һәм дөньяда һәм дә әхирәттә коткарачак әсәрләр, хезмәтләргә һәм нәселләргә бик нык итеп игътибар бирү мәҗбүриятендәбез. Хакны таныган, Хакның хәтерен һич бер хәтергә фида итәлмәс. Чөнки Хакның хәтере галидер - бөектер.

Шагыйр ничек матур әйткән:

**"Җаһил улемле, зәлем улемле, хаклы булу күвәт,**
**Хакның йөзе көлсә елмаер бәшәрият".**

Мөселманның истикрарлы - яки дәвамлы рәвештә ныклы булуы, истикамәттән - яки тугырылыктан аерылмаудадыр.

Хәзрәте Мәүләнәнең дигәне кебек: "Һәр җилгә ыкылган кебек иелсәң-бөгелсәң - таулар кадәр булсаң да бер кылган кадәр кадерең булмас. Ягъни адәм була алмасаң һәм Хак сафларында урыныңны таба алмасаң бер үлән кадәрдә дәрәҗәң булмас, кылганга да тиң булмассың. Шулай булгач, истикамәт сәхибе бул, урыныңны тап, юнәлешеңне бел, Хакка кол бул...".

Кадерле кардәшләрем! Үзен манкортлык хәленә китергән, шөгерсезләшкән һәм кем икәннәрен белмәгән милләтләрнең киләчәге булалмас, ныгый алмаслар. Бөтен кайгысы дөнья малы гына булган һәм үз кыйммәтләрен югалткан милләтләр, бар буларын дәвам итәлмәячәк. Димәк башларыбызны Хак белеме белән, яшәүебезне Ислам гамәлләре белән, күңелебезне чын гыйшык белән, карыныбызны хәләл ризык белән туйдырыйк, ялгыш юлларда башыбызны ватмыйк. Хакка сыгыныйк, котылуны Хакта эзлик. Өйрәнеп, яшик...

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рамаҙан 2010 миләди йыл**
**1431 һижри йыл.**

| Рамаҙан | Аҙна көндәре | Август, Сентябрь | Сәхәр (тамамлау) | Иртәнге намаҙ | Өйлә нам. | Икен. нам. | Ауыҙ асыу, Аҡшам. | Йәстү намаҙы, тәрәүих |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шаршамбы | 11 | 4.43 | 5.13 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.50 |
| 2 | Кесе йома | 12 | 4.45 | 5.15 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.50 |
| 3 | Йома | 13 | 4.47 | 5.17 | 14.30 | 20.24 | 21.54 | 23.50 |
| 4 | Шәмбе | 14 | 4.49 | 5.19 | 14.30 | 20.22 | 21.52 | 23.50 |
| 5 | Йәкшәмбе | 15 | 4.51 | 5.21 | 14.30 | 20.19 | 21.49 | 23.50 |
| 6 | Дүшәмбе | 16 | 4.53 | 5.23 | 14.30 | 20.17 | 21.47 | 23.45 |
| 7 | Шишәмбе | 17 | 4.55 | 5.25 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.45 |
| 8 | Шаршамбы | 18 | 4.57 | 5.27 | 14.30 | 20.13 | 21.43 | 23.45 |
| 9 | Кесе йома | 19 | 4.58 | 5.28 | 14.30 | 20.10 | 21.40 | 23.40 |
| 10 | Йома | 20 | 5.00 | 5.30 | 14.30 | 20.08 | 21.38 | 23.40 |
| 11 | Шәмбе | 21 | 5.02 | 5.32 | 14.30 | 20.06 | 21.36 | 23.35 |
| 12 | Йәкшәмбе | 22 | 5.04 | 5.34 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.35 |
| 13 | Дүшәмбе | 23 | 5.06 | 5.36 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.30 |
| 14 | Шишәмбе | 24 | 5.08 | 5.38 | 14.30 | 19.59 | 21.29 | 23.30 |
| 15 | Шаршамбы | 25 | 5.09 | 5.39 | 14.30 | 19.56 | 21.26 | 23.25 |
| 16 | Кесе йома | 26 | 5.11 | 5.41 | 14.30 | 19.54 | 21.24 | 23.25 |
| 17 | Йома | 27 | 5.13 | 5.43 | 14.30 | 19.51 | 21.21 | 23.20 |
| 18 | Шәмбе | 28 | 5.15 | 5.45 | 14.30 | 19.49 | 21.19 | 23.20 |
| 19 | Йәкшәмбе | 29 | 5.17 | 5.47 | 14.30 | 19.47 | 21.17 | 23.15 |
| 20 | Дүшәмбе | 30 | 5.19 | 5.49 | 14.30 | 19.44 | 21.14 | 23.15 |
| 21 | Шишәмбе | 31 | 5.21 | 5.51 | 14.30 | 19.42 | 21.12 | 23.10 |
| 22 | Шаршамбы | 1 | 5.22 | 5.52 | 14.30 | 19.39 | 21.09 | 23.10 |
| 23 | Кесе йома | 2 | 5.24 | 5.54 | 14.30 | 19.37 | 21.07 | 23.05 |
| 24 | Йома | 3 | 5.26 | 5.56 | 14.30 | 19.34 | 21.04 | 23.05 |
| 25 | Шәмбе | 4 | 5.28 | 5.58 | 14.30 | 19.32 | 21.02 | 23.00 |
| 26 | Йәкшәмбе | 5 | 5.30 | 6.00 | 14.30 | 19.29 | 20.59 | 23.00 |
| 27 | Дүшәмбе | 6 | 5.32 | 6.02 | 14.30 | 19.27 | 20.57 | 22.55 |
| 28 | Шишәмбе | 7 | 5.33 | 6.03 | 14.30 | 19.24 | 20.54 | 22.55 |
| 29 | Шаршамбы | 8 | 5.35 | 6.05 | 14.30 | 19.22 | 20.52 | 22.50 |

## КРОССВОРД



**1.** Мәккә мөшрикләре табынган сыннар исеме.
**2.** Сары төстәге кыйммәтле металл.
**3.** Мөселманнарның кыйбласы булган изге бина.
**4.** Ир-атларга гына хас зиннәт.
**5.** Иген сабагының бөртекле өлеше.
**6.** Киемнең тузган яки ертылган урынына сала торган тукыма кисәге.
**7.** Мәзәкче, акыл иясе, хәким.
**8.** Бер җепкә тезелеп оча торган күчмә кош исеме.
**9.** Юкә кабыгыннан үргән аяк киеме.
**10.** Ит белән пешергән ризык исеме.
**11.** Танылган шагыйребез, хикмәт иясе.
**12.** Җырларда җырлана торган тау исеме.
**13.** Кыш көне генә була торган ак бөртекләр.
**14.** Гарәп язуы белән матурлап нәкышләнгән кеше исеме.
**15.** Җиләкләре тәмле булган чәнечкеле куак исеме.
**16.** Зәкәрия пәйгамбәрнең улы - бөек нәби. (Кире яктан укырга).
**17.** Җир вә күкләрне һәм һәммәбезне бар иткән Илаһыбыз.
**18.** Берәр эш белән кәсеп иткән кеше.
**19.** Тәмлеткечләр салган томат исеме.
**20.** Кызларда һәм каеннарда була торган зиннәтләнү әйбере.
**21.** Бала сүзенең икенче өлеше.
**22.** Госманлы дәүләтенең башкаласы. (Астан өскә таба укырга).

**Кроссворд җаваплары ("Рисәләт", №7)**

1. Гүзәл;
2. бал;
3. яшел;
4. карабаг;
5. өммәт;
6. китап;
7. бөгелмә;
8. каймак;
9. та;
10. әннә;
11. яра;
12. ярангәл;
13. иртә;
14. Мөхәммәд;
15. аяк;
16. Камырбатыр;
17. чәчәк;
18. гүр;
19. байрак;
20. моң;
21. Гөлбикә;
22. бикә;
23. пәйгамбәр;
24. ля;
25. кәлтә;
26. татар;
27. падишаһ.